**СОВЕТ ДЕРЖАВИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422620,Татарстан, с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422620 Державино авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

**2025 елның 30 апреле** **24 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры вазыйфаи окладыкүләмен арттыру турында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш), Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 24 апрелендәге 8-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның хезмәт хакы түбәндәге зурлыкта билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны белән муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| --- | --- |
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш бухгалтер | 28 200 рублей |

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге башкарма комитетының штат расписаниесенә баш бухгалтер вазифасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 мең кешедән артык.».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Державино**
**авыл җирлеге Советы рәисе: И.И.Камалиева**